МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от “ 09 ” марта 2016** **№ 94**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөрту һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкала раслау хакында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкаланы расларга.

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

3. Элеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны транспорт идарәсе мөдире А.В. Сидоровка йокләргә.

Министр урынбасары А.В. Егоров

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
2016 елның 9 мартындагы
94 нче номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкала**

| № т/с | Критерийлар / параметрлар | Таләпләргә туры килә | Таләпләргә туры килми |
|---|---|---|---|
| 1. | Ачык конкурс үткәреләчәк датага кадәрге ел дәвамында кешеләр үлеменә яисә гражданнарның сәламәтлегенә зыян салуга китергән һәм юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар яисә аларның хезмәткәрләре гаебе белән килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтләре саны (ачык конкурс үткәреләчәк датага кадәрге ел дәвамында юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар карамагында булган транспорт чараларының уртача санынннан чыгып исәпләнә)<br><br>Ачык конкурста катнашуга заявкалар салынган конвертларны ачу көненә кадәрге 1 ел эчендә булган юл-транспорт һәлакәтләре саны 0 (нольгә) тигез<br><br>Искәрмә:<br>эшләү тәҗрибәсе булмаган очракта әлеге критерий исәпкә алынмый | 10 | 0 |
| 2. | Юридик затның, индивидуаль эшкуарның яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның даими рәвештә пасажирлар йөртү һәм багаж ташу тәҗрибәсе (шул исәптән әлеге маршрутта) (дәүләт контрактларын үтәү, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында таныклыклар, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары | эшләгән һәр ел өчен 1 балл, иң күбе 10 балл | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нигезендә бирелгән башка документлар белән расланган булырга тиеш) | | |
| 3. | Юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен тәкъдим итә торган транспорт чараларының пассажирлар йөртү һәм багаж ташу сыйфатына тәэсир итә торган характеристикалары (кондиционер булу, хәрәкәтләре чикләнгән пассажирларны, балалар коляскасы белән булган пассажирларны йөртү җайланмалары булу һәм башка характеристикалар) | | |
| 3.1. | Хәрәкәт составы җитештерелгән ел:<br><br>эшләү өчен 100% хәрәкәт составы булу (һәр берәмлеге ачык конкурс үткәрелә торган елга кадәрге 1 ел эчендә җитештерелгән)<br><br>эшләү өчен 70% хәрәкәт составы булу (һәр берәмлеге ачык конкурс үткәрелә торган елга кадәрге 1 ел эчендә җитештерелгән)<br><br>эшләү өчен 40% хәрәкәт составы булу (һәр берәмлеге ачык конкурс үткәрелә торган елга кадәрге 1 ел эчендә җитештерелгән) | 15<br><br>10<br><br>5 | 0<br><br>0<br><br>0 |
| 3.2. | Экологик күрсәткечләр (һәр берәмлеккә исәпләгәндә):<br>ЕВРО-6 двигателе<br>ЕВРО-5 двигателе<br>ЕВРО-4 двигателе | 0,3<br>0,2<br>0,1 | 0<br>0<br>0 |
| 3.3. | Техник структура:<br><br>Эшләү өчен Лотка туры килә торган, таләп ителә торган класслы хәрәкәт составы булу, һәр берәмлеккә исәпләгәндә | 0,2 | 0,1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.4. | Гражданнарның аерым категорияләре өчен транспорттан файдалану уңайлыклары:<br><br>Хәрәкәтләре чикләнгән пассажирларны, балалар коляскасы белән булган пассажирларны йөртү өчен җиһазландырылган бер берәмлек һәм аннан күбрәк хәрәкәт составы булу | 2 | 0 |
| 3.5. | Кондиционер булу (һәр транспорт чарасы өчен) | 1 | 0 |
| 3.6. | Транспорт чараларының йөртүчеләр тарафыннан хәрәкәт, хезмәт һәм ял режимнарын үтәүне тикшереп торуның техник чаралары (тахографлар) белән җиһазландырылган булуы, бер берәмлеккә исәпләгәндә<br>Әлеге критерий 50 км дан озынрак муниципальара маршрутларда гына исәпкә алына | 0,2 | 0 |
| 3.7. | Ачык конкурс  үткәрү турындагы хәбәрдә һәм конкурс документациясендә хәрәкәт составына карата куелган таләпләргә туры килә торган хәрәкәт составы булу:<br><br>ташучы милкендә (һәр транспорт чарасы өчен)<br><br>законлы башка нигезләрдә<br>(һәр транспорт чарасы өчен)<br><br>ачык конкурс үткәрү турындагы хәбәрдә һәм конкурс документациясендә бәян ителгән таләпләргә туры килә торган хәрәкәт составын заявкалар салынган конвертларны ачкан көннән алып унбиш көн эчендә сатып алу һәм (яисә) кайтару йөкләмәләрен раслый торган документлар булу | 15<br><br>10<br><br>0 | 0<br><br>0<br><br>0 |
| 4. | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык гамәлдә булган чорда даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | транспорт чараларын эксплуатацияләүнең максималь срогы | | |
| 4.1. | Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булу чоры тәмамланган вакытка маршрутта файдаланыла торган транспорт чараларын эксплуатацияләү срогы<br><br>5 ел (һәр транспорт чарасы өчен);<br><br>5 – 10 ел (һәр транспорт чарасы өчен);<br><br>10 –15 ел (һәр транспорт чарасы өчен). | 1<br><br>0,8<br><br>0,6 | 0<br><br>0<br><br>0 |